**Информационная газета** **Учредитель Администрация МБОУ «Сармановская СОШ»**

# Первая школа

Декабрь, 2020г. **Выпуск №35**

## Сегодня в номере


- Слово директору школы! с.1
- Как встретить год Быка? с.2
- Итоги I четверти с.3
- Спорт, спорт, спорт... с.4
- Әдәби марафон 4-5б.
- Мәктәптә ял лагеры 5б.
- •Беренче тапкыр укырга 5-6
- Әниләр бәйрәме 6б.
- Классные часы с.7
- Мәктәпнең зур югалтуы-8
- С днем рождения! с.9


## *Праздничный выпуск №35*



Хөрмәтле укучылар һәм укытучылар!

Менә декабрьнең соңгы көннәренә дә аяк бастык. Тиздән календарьдагы иң күркәм, иң эчкерсез, күңелле бәйрәм - Яңа ел житә. Әлбәттә инде без - укытучылар һәм укучылар өчен ул күңелле мәшәкатьләр бәйрәме. Чыршы бәйрәмнәре уздырасы, бүләкләр, яңа ел күчтәнәчләре әзерлисе бар. Шул мәшәкатьләр өстенә әле уңышлы гына чирек тәмамлыйсы...

Барыгызны да якынлашып килүче Яңа ел белән чын күңелдән котлыйм! Эшегездә, укуыгызда, тормышыгызда зур уңышлар юлдаш булсын! Ходай тәгалә саулык-сәламәтлектән аермасын, гаиләләребезгә тынычлык бирсен, кайгы - хәсрәт күрсәтмәсен. Яңа Үгез елы укытучыларны укучыларының уңышлары белән сөендерсен.

Әлеге искиткеч һәм барыбыз да яраткан бәйрәм уңаеннан иң изге теләкләрне кабул итеп алыгыз. Яңа елны, туган һәр яңа көнне елмаеп, зур өметләр һәм хыяллар белән каршы алыгыз! Күңелегез саф, хисләрегез эчкерсез, хыялларыгыз якты һәм матур булсын. Бәйрәмнәрегез мөбәрәк, табыннарыгыз түгәрәк булсын!

Яңа елда яңа бәхет яңа ачышлар көтә,
Барлык булган борчуларны иске ел алып китә.
Бәхетле булыгыз дуслар, кайгы хәсрәт читләсен
Елмаюлар йөзегездән мизгелгә дә китмәсен!

*Сабирҗанова Гөлназ Тәвис кызы*




Год, следующий после високосного, обещает быть спокойным. Он пройдет в трудах - над собой, работой, отношениями. Все, что вы вложите в этом году, вернется в удвоенном виде. Бык любит честных и ответственных. Потрудитесь немного, чтобы расположить к себе этот знак, и он вам ответит благосклонностью и дружелюбием.

Бык не верит в быстрое богатство, он идет к успеху своей дорогой, где всего добивается упорным трудом. Поэтому легких путей искать не стоит.

В семейном плане всегда царит покой и умиротворение. Бык - уверенный в себе и спокойный знак, поэтому от года ждать сильных потрясений не стоит. Уделяйте внимание себе, своей семье - это все, что бык так уважает и будет всячески способствовать вашему благополучию в этих сферах.

## Как встречать год Быка?

Как мы уже отмечали, бык - животное консервативное, поэтому лучшим вариантом встречи Нового Года 2021 станет семейный праздник. На столе должна быть простая, но обильная еда: мясо с картошкой, привычные зимние салаты, а также много растительной пищи. Заморских деликатесов и экзотических блюд лучше избегать. Считается, что блюда из говядины могут обидеть хозяина года, поэтому отдайте предпочтение другим видам мяса. Среди напитков популярное место займут морсы, натуральные соки, компоты и ягодные настойки. Про десерт тоже не стоит забывать - хозяин года любит сладкое и ждет его на праздничном столе. Встречайте Новый год в семейном кругу и с близкими друзьями. Пусть это будет уютный домашний праздник, где всем легко и комфортно друг с другом. Бык - животное, любящее тепло и уют. Вместе украсьте место проведения, приготовьте праздничные блюда - хозяин года оценит такую сплоченность.

Так как 2021 - год Белого Металлического Быка, то и цветовую гамму следует выдерживать в этом стиле. Пусть это будут легкие платья светлых тонов, разбавьте белый цвет металлическим блеском (аксессуары или туфли), и Быка обязательно порадует такое внимание. Используйте одежду из натуральных материалов: шелк, хлопок, мех, но не перегружайте образ. Воздержитесь от нарядов красных цветов, чтобы не разгневать животное. Такая же цветовая гамма и все те же натуральные материалы (дерево, металл, камень) должны преобладать и в украшении жилища.

## Как нарядить дом к году Быка?

Обязательно поставьте на середину стола веточку сосны, на востоке она символизирует долголетие. И, конечно же, повесьте на елку талисман года — маленького быка: такое внимание ему польстит. И не забудьте при последних минутах уходящего года загадать свое самое заветное желание.


## Знаменитости, родившиеся в год Быка

Алла Пугачёва, Эдита Пьеха, Иннокентий Смоктуновский, Сергей Безруков, Анна Ахматова, Валентина Терешкова, Владимир Высоцкий, Наполеон Бонапарт, Ганс Христиан Андерсен, Маргарет Тэтчер, принцесса Диана, Уолт Дисней, Чарли Чаплин.

# Итоги I четверти


Всем ученикам, кроме 1, 10 и 11 классов, вывели четвертные оценки. Из аттестованных 392 учеников МБОУ «Сармановская СОШ»:
- отличников – 46, с одной «4» остались 13 учеников (в конце года было 14);
- ударников – 187, с одной «3» остались 35 учеников (в конце года было 25);
- троечников – 158.

**2-9 классы**





Успеваемость по школе – 99,74 %
Качество – 59,44 %

**Сравнительный анализ качества знаний уч-ся 2 – 9 классов за I четверть**
**(в сравнении с 2019/2020 уч. годом)**




Качество понизилось.




*Зам.директора по УР Исмагилова Гульназ Талгатовна*

## Спорт,спорт,спорт...



Мин, Киямов Тимур, Сарманда туганмын, беренче мәктәпнең 5 нче "б" сыйныфында укыйм. Укуым яхшы. Бик тырышам. Укудан буш вакытымда футбол түгәрәгенә йөрим. Мин анда беренче класстан ук һәм бик теләп шөгыльләнәм. Тренировкалар атнага өч тапкыр була. Минем тренерым Илсур Җәүдәтович. Без төрле шәһәрләрдә үтә торган ярышларда күп катнашабыз. Әлмәт, Минзәлә, Баулы, Җәлил, Актаныш, Мактама, Актүбә шәһәрләрендә булдык.

Әле күптән түгел генә Актаныште үткән футбол ярышында үзебезнең көчне сынап кайттык. Ярыш республика күләмендәге иде. Без Сарман районы данын якладык. Бу безнең командага җаваплылык өстәде. Төрле шәһәрдән барлыгы 12 команда иде. Бу - көнчыгыш зона. Ярышлар ике көн булды. Безгә район җитәкчелеге автобус бирде. Актаныш безне бик җылы каршы алды. Командабыз белән без "Иман" спорт сараенда яшәдек. Үзебезнең яшьтәшләр белән аралашу миңа бик ошады. Минем белән берлектә сыйныфташларым Ризатдинов Азат, Вәлиев Айзат, Фәйзуллин Илназ һәм 5нче а сыйныфыннан Сафин Айзат та катнашты. Командалар бик көчле составта килгәннәр. Ләкин без дә сынатмадык. Үзебезнең осталыкны һәм үҗәтлекне күрсәттек, лаеклы дүртенче урынны алдык. Бу бик зур нәтиҗә. Тренерыбызның йөзенә кызыллык китермичә, алга таба да зур үрләр яуларбыз.

Бу спорт төре миңа бик охшый. Командабыз белән бергә һәм бердәм тырышып уйнарбыз. Үскәч минем хыялым футболист булу.

*Кыямов Тимур, 5нче Б сыйныфы укучысы*

## Әдәби Марафон

20 октябрьдә Казан шәһәренең "Пирамида" мәдәни-күңел ачу үзәгендә XIII Дөньякүләм Әдәби марафон тантанасы үтте.

Аңа Россиянең төрле төбәкләреннән - Башкортстан, Удмуртия һәм Чувашия Республикасы, Киров, Омск, Чиләбе һәм Пермь өлкәләреннән һәм Санкт-Петербург шәһәреннән үз туган телен, татар әдәбиятын, мәдәниятен яраткан һәм башкаларны да кулларына китап алып укырга чакырган марафончылар килгән иде. Марафонда Австралия һәм Согуд Гарәбстанынннан да катнашучылар булган. Анда безнең мәктәпнең 12 укытучысы һәм 8 укучысы (Мәүләвиева А., Хатипова И, Хатипов Р., Шафигуллина А. (2А), Вәлиев Т., Хайбрахманова И., Хөсәенова Я. (2В), Хайбрахманов Б. (4а) бик теләп катнашты, сәхнәгә менеп, дипломнарын алдылар. Китап укучыларны котларга республикабыз җитәкчелегеннән, Дәүләт Советыннан, министрлыклардан дәрәҗәле кунаклар, республика районнары җитәкчеләре, ВКонтакте һәм Википедия вәкилләре, танылган язучылар, шагыйрьләр, драматурглар һәм журналистлар килгән иде. Марафончылар аеруча Рабит Батулла, Данил Салихов, Зифа Кадыйрова, Нәбирә Гыйматдинова, Гөлсинә Галимуллина, Разил Вәлиев, Ләбиб Лерон, Йолдыз Шәрәпова кебек әдипләребезне күрергә теләгәннәр иде. Барысы да диярлек килделәр, бик теләп

китап укучылар белән бергә фотоларга төштеләр, сәхнәгә күтәрелделәр.

Бәйрәм барышында әдәби марафонда катнашкан барлык районнар да сәхнәгә чыгып, истәлекле бүләкләр алды. Ә инде бәйгенең иң кульминацион мизгеле бәйге финалистлары арасында призлы урыннарны билгеләү була. Әлеге дәрәҗәле урыннар татар әдәбиятын ВК челтәрендә аеруча нык популярлаштырган, татар әдәбиятына карата иң нык кызыксыну һәм мәхәббәт тәрбияләгән марафончыларга бирелә. Бу марафонда беренче урында – Саба, икенчедә – Лениногорск, өченчедә Балтач һәм Казан әдәбият сөючеләре булдылар. Сарман районы китап сөючеләре дүртенче урында булдылар. Районыбыз - иҗади, сәнгатькә гашыйк, туган телен, мәдәниятен хөрмәт итүче, үстерүче район. Киләсе марафонда безнең район да сәхнәләрне тутырып, җиңүчеләр рәтендә торыр, дигән ышаныч бар.

Бәйгенең ешлыгы - квартал саен. Марафон 1 гыйнвар, 1 апрель, 15 июль



(мәктәп укучылары өчен генә), 1 октябрь көннәрендә башланып китә һәм 21 көн дәвамында бара, биредә татарча яза һәм укый алган һәркем катнаша ала. Ә инде әдәби марафончылар рәтенә басарга теләүчеләр 2021 елның 1 гыйнварында башланып китәчәк XIV марафонда катнаша ала.

*Әдәби марафончы Уразаев Камил,*
*5нче А сыйныфы укучысы*

## Мәктәп яны лагеренда ял



Һәр ата-ана баласының ялы файдалы һәм күңелле үтсен дип тели. Әлбәттә, эти-әниләр һәм мәктәп арасында тыгыз бәйләнеш оештырылган булса, бу үз нәтиҗәләрен бирә.

Көзге каникуллар вакытында мәктәп яны лагере тагын балаларны үз янына җыйды. Җәй көне лагерьда пандемия аркасында ял итә алмаган балалар сөенешеп ял итәргә килделәр.

Укучыларның ялы күңелле үтсен өчен укытучылар барсын да эшләделәр. Лагерь тормышы үз тәртибе белән тыныч кына башланды: иртән көн саен, саф һавада зарядка, иртәнге аш, отрядларда төрле – төрле уеннар, шөгыльләр, экскурсияләр. Лагерь тормышы Халыклар бердәмлеге көнен искә алу белән дәвам итте. Иң матур мизгелләр булып истә калучы бәйрәм – көзге бал булды. Бәрәңге җыю, олы резин итекләр киеп йөгерү, тотып карап яшелчәләрне тану уеннары, төрле спорт, шахмат ярышлары бик кызыклы үтте. Кышкы каникуллар чорында да мәктәп янын лагере булсын иде дигән теләк белдерделәр.

*Лагерь җитәкчесе Гатина Гөлназ Рафисовна*

## Беренче тапкыр “укырга, укырга, укырга...”

Сарман урта мәктәбендә октябрь аеннан мәктәпкәчә әзерлек курслары ачылды. Курсларда 49 бала йөри. Һәр атнаның шимбә көнендә алар зур ашкыну белән мәктәпкә киләләр. Күзләре янып тора, өйрәнү теләкләре көчле. Без, укытучылар, аларның шушы

теләкләре югалмасын өчен дәресләрне кызыклы, уен формасында алып барырга тырышабыз. Аларның фикерләү сәләтләрен үстерү, кул һәм бармакларның төгәл координацияле хәрәкәтләрен үстерү, авазларны дөрес әйтә белү, команда белән эшләү алымнарын өйрәтәбез. Дәресләр кызыклы һәм күңелле үтә: тизәйткечләр кабатлыйбыз, әкиятләр куябыз, кул эшләрен шактый гына эшлибез һ.б. Сөйләгәнне тыңлый белү, укыганның мәгънәсен аңлап, дөрес җөмлә төзеп сөйли белү күнекмәләрен бирәбез. Әти – әниләргә дә күзәтүләр буенча үз киңәшләребезне бирәбез. Вакытында дөрес киңәш бирү дә кайбер кимчелекләрне җиңәргә ярдәм итәр дип ышанабыз.

Әйе, баланы мәктәпкә әзерләү җиңел эш түгел. Баланың уңышлы укуы, аның мәктәпкә ничек әзерләнгән булуына бәйле. Укытучы, тәрбияче, әти – әни бер сүздә булып, баланы төрле яктан үстерсәк, бала мәктәпкә җиңел кереп китәр, уку да аңа җиңел бирелер дип уйлыйм.

*Александрова Әлфинур Әбүзәровна, башлангыч сыйныф укытучысы.*




## Кояш гомере телим мин әнием сиңа!

Әни-җирдә иң газиз,иң якын кеше, чөнки ул сине тудырган, күкрәк сөтен имезгән, җыр көйләп бишектә тибрәткән, беренче елмаюыңны күреп куанган, туган телне өйрәткән, халык моңын күңеленә сеңдергән. Әниләрнең сиңа кылган изгелеген санап бетерү мөмкинме соң?

28 нче ноябрьдә, айның соңгы якшәмбесендә Әниләр көне булып узды. Безнең мәктәптә Әниләргә багышланган “Әниемә рәхмәт әйтәм” исемле котлау открыткалары бәйгесе үткәрелде. Мин дә бирердә үз открыткамны ясап катнаштым. Безнең 6нчы б сыйныфы да бу бәйрәмнән читтә калмады. Без әниләргә видеокотлау төшереп җибәрдек, һәрберебез үз өлешен кертте.

Минем уйлавымча, бөтен кеше үзенең әнисен ярата. Менә мин үземнең әниемне матур, игелекле, намуслы һәм эшчән кеше булуы өчен яратам. Аның исеме - Гөлшат. Ул Сарманда архив бүлеге җитәкчесе булып эшли. Бәйрәм көнне мин аны котлап олы чәчәк бәйләме бүләк иттем. Мин үземнең әниемә исәнлек, саулык һәм озын гомер телим. Дөньядагы бөтен әниләрне дә бәйрәм белән котлыйм!

Әни!Әни җирдә иң кирәкле кеше.
Әниләрнең белик кадерен
Җил-давылдан саклап үстергән ул
Кызганмыйча бөтен гомерен.
Әни бит ул изге җанлы кеше.
Бала өчен бирә барсын да,
Кадерләрен белик янда чакта,
Котлап торыйк туар һәр таңда.



*Солтангалиева Айгөл, 6нчы б сыйныфы укучысы*

## Классные часы




Классные часы – это обязательные воспитательные мероприятия для школьников с первого по одиннадцатый класс, посвященные разнообразным темам, зависящим от возраста учеников, проблем, с которыми им приходится сталкиваться в повседневной жизни, их интересов. Классные часы и беседы на некоторые темы совершенно обязательны к проведению. Для учеников начальной школы это уроки, рассказывающие о правилах дорожного движения, пожарной безопасности, доброте; для старшеклассников – о патриотизме, нравственности, этике и культуре. Тематика сценариев уроков подобрана таким образом, чтобы сформировать каждого ученика как личность и подготовить его ко взрослой жизни.

Согласно воспитательному плану школы и Положению о классном руководителе классные часы в нашей школе проводятся 1 раз в неделю в четверг. В основном они посвящены таким направлениям как здоровье, правопорядок, учеба, моральные ценности, патриотизм и т.д. В ноябре месяце, например, классные часы проводились на следующие темы: “Отказ от курения”, “ПДД” и “День неизвестного солдата”. Особенно интересно детям, когда на эти беседы приходят представители тех или иных профессий. Я надеюсь, что учащимся интересны и полезны проводить такие мероприятия.

*Салихов Фарит Альфисович,*
*зам.директора по ВР*

## *Мәктәпнең зур югалтуы*

Данияр Дөлфәтович, Данияр абый... Бу исем күпләргә таныш. Узган атнада аның вакытсыз вафат булуы турында кайгылы хәбәр килеп иреште. Кеше турында аның хезмәте сөйли. Кайсы гына эшкә тотынмасын, ул аны иң югары дәрәҗәгә җиткереп башкарды: республикакүләм олимпиадаларында аның укучылары һәрвакыт призлы урыннар яулады, җәй айларында басуда уңыш җыюда да алдынгылар рәтендә булды ул. Ә гармун сыздырып җибәрсәме?!..

Ул һәрвакыт беренчелеккә омтылды, коллективта лидер булды, мәктәптән кайтып кермәде. Данияр Дөлфәт улы районда гына түгел, республиканың иң көчле укытучыларының берсе, укучыларның яраткан тренеры иде.

Әле һаман ышанып булмый. Спортзалга кергәч, аның “Внимание! Строимся!” дигән көр тавышы яңгырар сыман. Ул балалар белән генә түгел, укытучылар арасында да команда ясап, ярышлар уздырды. Гәүдәсе әзмәвердәй, көч сынашсаң, яшь егетләрне дә уздыра.

Һәрбер укучыга ул үзенчә карый һәм яраклашу юлын белә иде. Данияр абый безнең классны 5нче сыйныфтан бирле укытты, 7нче класстан бирле мин физкультура



олимпиадасында катнашам. Бу атнада да шушы олимпиадада катнашып, яхшы нәтиҗәләр күрсәттем дип уйлыйм. Данияр абыйсыз, һичшиксез, мондый югарылыкка ирешә алмас идек.

Районыбызда ул һәрвакыт зур ихтирамга лаек булды. Инде аны узган атнада соңгы юлга озаттык. Биредә өлкәннәр генә түгел, аны яраткан укучылар - без дә җыелган идек. Бик кызганыч. Данияр абый гадел, максатчан, шат йөзле, олы йөрәкле кеше булып хәтеребездә калачак.

*Фәрхетдинова Алия, 10нчы сыйныф укучысы*

# С днём рождения!

***Поздравляем с днём рождения!!!***

***<u>В декабре месяце справляют свои дни рождения наши педагоги:</u>***




*Хуснутдинова Ляйсан Талгатовна, учитель географии - 8 декабря*

*Калимуллина Эльвира Ануровна, педагог-организатор - 12 декабря*

*Рамазанова Эльмира Тамерьяновна, учитель русского языка и литературы – 17 декабря*

*Таепов Алмаз Мансурович, учитель технологии – 21 декабря. ЮБИЛЯР !!!*

***<u>В январе месяце справляют свои дни рождения наши педагоги:</u>***

*Махмутов Илдус Назифович, учитель истории и обществознания – 8 января,*

*Гатина Гульназ Рафисовна, учитель начальных классов - 10 января,*

*Мухлиева Гаухар Аухатовна, библиотекарь – 16 января,*

*Мусина Эльмира Ильфатовна, учитель математики - 19 января,*

*Рамазанова Раушания Наилевна, учитель родного языка и литературы – 26 января,*

*Файзуллина Зиля Муаммиловна, учитель биологии - 30 января.*